СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.01.2016 с. Татарское Бурнашево № 5-29

Бурнаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты, Бурнаш авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» Бурнаш авыл җирлеге Советының 2015 елның 17 декабрендәге 4-25 карары, Бурнаш авыл җирлеге башлыгының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 2015 елның 17 декабрендәге 28 номерлы карарлары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Бурнаш авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2016 елның 6 мартына җирле референдумны билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару мәсьәләсен хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:
- 900 м озынлыктагы Бурнаш авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә урнашкан, гомуми суммасы 242750 сумлык җирле әһәмияттәге юлларга чокырлар ямау ремонты.

ӘЙЕ ЮК.

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин